
**/Чал тарихта эзле без/**

### Яңа табылган китап




Күптән түгел безнең гарәп язулы иске китаплар тупланмасы тагын берничә басмага баеды. Аларны авыл мәчетенә Казан шәһәрендә яшәүче авылдашыбыз Раилә апа тапшырды. Шушы китаплар арасында Габдулла Тукайның “Балалар күңеле” дигән шигырьләр җыентыгы да бар. Бу китапның берничә фрагменты безнең тупланмада электән үк булса да, тулы нөсхәсе әле табылганы юк иде.

“Балалар күңеле” җыентыгы әле Тукай үзе исән вакытта 1910 нчы елда “Сабах” китапханәсе тарафыннан нәшер ителгән. Басманың кереш сүзендә аның махсус мәктәп балалары өчен чыгарылганлыгы турында әйтелә. Җыентыкка Тукайның барлыгы 21 шигыре кертелгән. Аларның күбесе хәзер дә укыту программаларына кертелгән. Менә аларның исемлеге: “Аллаһ Тәбәракә вә Тәгалә” (“Таян Аллага”), “Ана догасы”, “Туган тел”, “Бабай”, “Уянмас йокы”, “Ай һәм кояш”, “Җир йокысы”, “Кышка бер сүз”, “Кошларга”, “Сабыйга”, “Карлыгач”, “Кышкы кич”, “Бәхетле бала”, “Яхшы хәбәрләр”, “Бала белән күбәләк”, “Мәктәптә”, “Эш беткәч уйнарга ярый”, “Арба, чана, ат”, “Кәрханәдә”, “Китап”, “Кәҗә белән сарык хикәясе”. Иске имляны таныган укучылар әлеге шигырьләрне хәзер оригиналдан укый алачаклар.

*Рафик Насыйров, тарих укытучысы, тарих фәннәре кандидаты*

---

**/Безнең спорт/**

### Фаил Актанышны алды!

23-26 сентябрь көннәрендә Татарстанның Актаныш район үзәгендә җирлегендә классик шахмат төре буенча Кама аръягы Гран-При кубогы турнирының 4 нче этабы булып узды. Бу бәйгедә безнең мәктәпнең шахмат короле, V сыйныф укучысы Гафиятуллин Фаил дә катнашты. Турнир бик киеренке узды. Биредә Казан, Түбән Кама, Баулы, Әлмәт, Бөгелмә шәһәрләре, Актаныш, Лениногорск, Мамадыш, Минзәлә, Чистай районнары, Башкортстанның Октябрьск районы шахматчылары көч сынашты. Көндәшләрнең көчле уенына карамастан, Фаил I урынны алуга иреште. Аңа киләчәктә тагын да зуррак үрләр яулавын телибез. Афәрин, Фаил!



---

**/Котлыйбыз! /**




28 сентябрь көнне хезмәттәшебез, бакча төркеме тәрбиячесе Бәширова Альмира гаиләсендә бишенче бала буларак кызлары Мәдинә дөньяга килде. Альмира белән Әнвәрне иң зур шатлыклары – энҗе бөртегедәй кызлары туу белән котлыйбыз. Бүгенге көннән өегезнең яме тагын да артты. Җан җимешегез иманлы, тәүфыйклы, сау-сәламәт һәм бәхетле бала булып үссен.

*Мәктәп хезмәткәрләре*

---

9 сентябрьдә мәктәбебез җитәкчесе Насыйров Рафик абыйның, 10 сентябрьдә Гафиятуллина Зөлфия апаның туган көннәре. Хөрмәтле укытучылар! Сезне чын күңелдән гомер бәйрәмегез белән тәбрик итәбез. Сезгә озын гомер, сәламәтлек, гаилә иминлеге һәм иҗади уңышлар телибез. Укучыларыгыздан гел рәхмәт сүзләре генә ишетелсен!

14 сентябрьдә XI сыйныф укучысы Мөхәммәтова Рузиләнең туган көне. Аңа укуында һәм алда торган имтиханнарында уңышлар, ныклы сәламәтлек телибез. Барча теләкләреңә дә ирешергә язсын, Рузилә!




---

**/Күңелле тәнәфес /**

### Малайның исеме ничек булган?

Наза, Роза, Әсма, Динә исемле кызлар бер малай белән очрашалар. Үзләренең исемнәрен әйткәч, малайның исемен дә сорыйлар.

“Берегезнең исеменнән беренче хәрефне,
икенчегезнекеннән – икенче, өченчегездән – өченче,
дүртенчегезнең исеменнән дүртенче хәрефне алып бергә
тезгәч, минем исем килеп чыга” – дигән малай.

Малайның исеме ничек була?

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Сара Насыйрова
Виктория Нукина, Рузилә Мөхәммәтова
Зөлфирә Сафиуллина

---

# Мәктәп хәбәрчесе

№7 (№28) сентябрь 2021 ел

Түбән Майна урта мәктәбе гәзите

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru

## Беренче сентябрь – Белем бәйрәме белән дуслар!

**/ Укытучы сүзе /**

### Хәерле сәгатьтә!

Әле кайчан гына мәктәп шау-шудан тынып калып, укучыларын җәйге ялга озаткан иде. Инде менә тагын мәктәп ишегалды кабат күңелле балалар авазына, кыңгырауның шатлыклы чыңлавына күмелде.



Бүген барлык кешеләр өчен дә Белем бәйрәме. Чөнки мәктәп еллары һәрберебезнең хәтерендә гомерлеккә уелып калган якты дәвер ул. Бәйрәм чарасын тамаша кылырга килгән өлкәннәрдә бу чарада катнашу белән балачакның күңелле хатирәләрен яңарткандыр. Укучыларга килгәндә, алар өчен Беренче сентябрьдән төп шөгыльләре – белем алу эшчәнлеге башлана. Ә кемдер исә беренче тапкыр мәктәп бусагасын атлый. Җиде яшьлек керсез сабый бүген белем үрләрен яуларга керешә. Мәктәпкә аны кулыннан тотып беренче укытучысы алып керә. Беренче һәм бердәнбер укытучы барыбызны да белем иленә җитәкләп кертә. Аларның һәрчак ярдәмен тоеп, елдан-ел югарырак, катлаулырак белем киштәләренә үрлибез.

Мәктәп еллары атлап түгел, йөгереп уза. Вакытның сизелми дә үткәнен аңлыйбыз. Шуңа күрә, укучылар, булган һәр мизгелнең кадерен белеп, мөмкинлекләрне кулдан ычкындырмый белем алырга ашыгыгыз. Уку – җиңел эш түгел, юкка гына аны энә белән кое казуга тиңләмәгәннәр. Шуңа да карамастан, белем алу – ул маҗаралы да, мавыктыргыч та, күңелле дә. Мәгърифәт рухы бөркеп торган мәктәбебез диварлары үзе сезгә белем үрләрен яуларга ярдәм итәр. Чөнки ул синең туган мәктәбең. Монда сезне аңлаучы, яклаучы, бар көчен һәм вакытын кызгынмыйча белем бирергә әзер торган укытучы апа-абыйларыгыз. Шулай булгач, кадерле укучылар, белем алырга сезгә һәр яктан ярдәм бар. Синнән тырышлык һәм җаваплылык кына кирәк мәктәбең. Үзеңә бераз кызыксыну өстәргә, иптәшләреңә карата сабыр булырга, укытучыларыңа хөрмәт, тирә-ягыңа сакчыл караш та булса, синең белән бар да әйбәт булачак.

Хөрмәтле балалар, әти-әниләр, мәктәп хезмәткәрләре! Сезне Беренче сентябрь – Белем көне – Беренче кыңгырау бәйрәме белән котларга рөхсәт итегез. Кадерле укучылар, мәктәп дигән могҗизалы ил ишекләрен сезгә киң итеп ачсын. Исәнлектә-саулыкта, дөньябызның тынычлыгына сөенә-сөенә белем алыйк.

*Түбән Майна урта мәктәбенең укытучылар коллективы*




### Укучыларга теләк

Белем илендә яшәгез
Елмаеп, шатланышып.
Дәреслекләрне укыгыз
Иренмичә, тырышып.

Бирсен Сезгә һәр яңа көн
Яңа ачыш, шатлыклар.
Тирәк булсын яңа җирдә
Яңа иптәш һәм дуслар.

Мәктәп еллары үтә тиз
Кадерләгез һәр көнен.
Туплап игътибарыгызны
Үзләштерегез белем.

Мөгаллимнәр биргән сабак
Тормышта булыр маяк.
Сикәлтәле юлларында
Барырга туры атлап.

*Рафик Исмәгыйлев,*
*пенсионер укытучы*

---

**/Рәсми хәбәрләр /**

### 2021/2022-нче уку елы башланды

2021/2022 нче уку елын мәктәп гадәти эшчәнлек тәртибендә башлый. Уку елы башына мәктәптә укучылар саны – 51, бакча төркемендә тәрбияләнүчеләр – 10 бала тәшкил итте. Беренче сыйныфка 6 бала, бишенчегә 7, унынчыга 4 укучы кабул ителде. Укучылардан 41 бала Түбән Майнада яшәүчеләр, 10 бала күрше авыллардан йөреп укучылар. Шулардан 6 укучы Такталы авылыннан, 2шәр укучы Яңа Әдәм һәм Иске Әдәм авылларыннан. Читтән килүче укучыларны мәктәп автобусы узган еллардагы режим һәм маршрут буенча йөртәчәк. Укытучылар коллективы составында үзгәрешләр юк. Укучылар саны 50 дән артык булганлыктан, район мәгариф бүлеге башлангыч сыйныфларны 4 класс-комплект белән укытырга рөхсәт бирде.

*Илдар Хәбибуллин, укыту эшләре буенча директор урынбасары*

*/Безнең бәйрәмнәр /*



## 27 нче сентябрь - тәрбиячеләр көне

Бу көн һәр сабый баланы яратып, аның өчен барлык тырышлыгын куйган тәрбияче һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларга белем бирүче укытучылар хезмәтен олылау көне. Баланың якын дусты, сердәшчесе, тормышка беренче адымнарын ясарга ярдәм итүче мөгаллиме аерым игътибарга лаек! Чөнки алар алдында мөһимнәрдән-мөһим бурычлар тора: балаларга ике телне өйрәтү, аларны халкыбызның тарихы, матур йола, гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре, мәдәнияте белән таныштыру. Тәрбияче төрле яктан үсеш алган, үзендә балалар яратырлык сыйфатларны туплаган да булырга тиеш.

Мәктәпкәчә яшьтәге балалар белән эшләүче **Насыйрова Гөлүсә, Бәширова Альмира, Хадиуллина Фәния, Әхмәрова Рушания апаларга** җаваплы, катлаулы һәм мактаулы хезмәтләрендә уңышлар телибез. Сабыйлар өчен һәрчак яраткан "Апа" булып, нәниләрнең хөрмәтләрен тоеп озак еллар нәтиҗәле эшләргә язсын.

***"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе.***

*/Өлкәннәр киңәше /*

## *Чананы җәйдән әзерлә*

Уку елы башланырга өлгерми, тиз арада имтиханнар тапшыра торган җаваплы чор да килеп җитә. Укучыларга, бигрәк тә чыгарылыш сыйныфларга, бу турыда һәрдаим искәртеп киләбез. Укучы чыгарылыш сыйныфына җиткәндә төгәл итеп бараса уку йортын, ягъни сайлыйсы һөнәренә нинди имтиханнар тапшырасын белергә тиеш. Әгәр ул гуманитар юнәлеш булачак икән, димәк, җәмгыять белеме, әдәбият, еш кына инглиз теле, фәлсәфә һәм юридик факультетларга керер өчен тарих кирәк булачак. Техник юнәлеш өстенлек бирәсең икән, профиль математика бирәсе барлыгын истә тот, аңа әзерлекне 2-3 ел алдан башласаң яхшы булуын да онытма. Шунлыктан, халыкның билгеле мәкален **"Чананы җәйдән, укучыны имтиханнарга берничә ел алдан әзерлә"** диеп үзгәртсәк, бүгенге вәзгыятькә бик төгәл туры киләчәк.

Имтиханнар мәсьәләсендә укучылар әти-әниләрне борчыган төп сораулар түбәндәгеләрдән гыйбарәт.

**1. Дәүләт йомгаклау аттестациясенә кайчан әзерләнә башларга?**

Иң идеаль вариант – имтиханнарга 1 ел кала ныклап әзерләнә башларга кирәк. Әлеге вакыт эчендә укучының, бар материалны кабатлап чыгып, сынауларын югары баллга тапшыру ихтималы зур. Техник һәм табигать фәннәреннән (математика, физика, химия, биология) имтихан тапшыруга әзерлекне 2 ел алдан башлау отышлырак. Олимпиадаларга йөрүче укучылар өчен БДИга әзерлек эше бермә-бер кими: имтиханнарда биремнәр күпкә җиңелрәк.

Укучы еш кына: "Язга кадәр вакыт бииик күп, әзерләнергә өлгерермен әле", – диярgә ярата. Тик әнә шул "күп" вакыттан Яңа ел, май бәйрәмнәрен, авырып китү ихтималын һәм башка шундый очракларны сызып атсак, көннәрнең санаулы икәнен аңларга мөмкин. Әле бит шул вакыт эчендә 10 ел дәвамында алган белемнәрне яңартырга өлгерергә кирәк. Шуны аңлап алып, әзерлекне озакка сузмасаң, үкенмәссең.

**2. БДИны яхшы тапшырыр өчен нәрсә кирәк: тест чишә белүме, гомуми белемнәрме?**

Моннан 10-15 ел элек, әле БДИ кертеп кенә яткан чорларда ул тестлардан гына тора иде. Һәр ел саен имтиханны үзгәртәләр, биремнәрен катлауландыралар. Мисал өчен, хәзер бер сорауда берничә җавапны билгеләргә кирәк. Бигрәк тә яңа стандартлар белән укучылар өчен биремнәр кабат катлауландырылды. Мисал өчен, рус теленнән инша өлешендә әдәбияттән аргументлар китерүне шулай ук бетерделәр, чөнки укучылар аларны имтиханга кергәндә ятлап бетерә иде. Хәзер инша тәкъдим ителгән текст нигезендә генә языла, аны шәрехләүгә кайтып калачак.

3. **Имтиханнарга үзлектән әзерләнеп буламы?**

Әгәр кызләрең "уку" дип яна һәм син белем алырга һәрьяклап әзер икән, әлбәттә, син бар материалны дәреслекләр аша гына да үзләштерә аласың. Шуның өстенә, хәзерге вакытта һәр укучы интернет челтәре ресурсларыннан кирәгенчә файдалану мөмкинлегенә ия. Безнең мәктәп очрагында укучыга күпкә ансатрак, чөнки укучылар аз, укытучы һәрчак ярдәмгә әзер.

4. **Өстәмә имтиханны кайсы фәннәрдән тапшырырга икәнлеген ничек хәл итәргә һәм ничә фән сайларга?**

Иң күп дигәндә 3-4 имтихан сайлагыз, аннан да артыкка алыну хаерлегә булмас. Көнегезне тәртипкә салып, уку вакытын телефоннардан башка гына, фикерне туплап ,тынычлап әзерләнергә кирәк. Әзерләнү барышында ял итеп алырга, саф һавада йөреп кереп, акыл хезмәте белән физик хәлне аралаштыру мөһим. Бу очракта әти-әниләр бала өчен иң зур терәк була алалар.

***Раушания Нәҗметдинова, рус теле һәм әдәбияты укытучысы***

*/Мәктәп тормышы /*



## Уңышлар җыелды

**"Эшләмәсәң эш көне, ни ашарсың кыш көне"**, дип әйтә безнең халык... Без – мәктәп укучылары, җәйге каникулда ял итеп кенә калмыйбыз, аны файдалы итеп үткәрергә тырышабыз. Мәктәпнең зур гына бакчасы бар. Анда суган, кишер, чөгендер,бәрәңге үстерәбез. Әлбәттә, алардан мул уңыш алу өчен җиренә җиткереп эшләргә кирәк. Без бакчада тырышып эшләмәсәк, ашханәбез өчен кышкылыкка яшелчәбез дә булмас иде. Моның өчен без чиратлашып укытучылар белән берлектә җәйге практикада эшлибез. Яшелчә һәм чәчәк түтәлләрен чүп үләннәреннән арындырабыз, су сибәбез, йомшартабыз. Мәктәп тирәсен матурлауда да шулай ук без тырышлык куябыз. Төрле чәчәкләр белән бизәлгән мәктәп ишегалды авылга килгән һәркемне сокландыра.

Инде менә үстергән уңышны җыеп алырга да вакыт җитте. Сентябрьнең матур бер көнендә мәктәп хезмәткәрләре һәм укучылар бергәләшеп бакчадагы көзге эшләрне башкардык. Хәзер инде барлык яшелчәләр дә җыелып, саклауга салынды.

***Виктория Нукина, Х сыйныф укучысы***

## *"Татарча диктант - 2021"*

11 нче сентябрдә Бөтендөнья күләмендә "Татарча диктант - 2021" акциясе узды. Үткән елларда да, быел да диктант язу пунктлары итеп китапханәләр, мәктәпләр, балалар бакчалары билгеләнде. "Татарча диктант" – бик кирәкле акция. Ул татар телен өйрәнүгә ихтыяҗны арттыра, кызыксындыру булдыра, мөстәкыйль рәвештә татар телен өйрәнүгә, дөрес язу күнекмәләрен үстерүгә этәргеч бирә, телебезгә хөрмәт тәрбияли.

Быел диктант халык язучысы Гомәр Бәширов истәлекләре буенча иде. Ул анда композитор Сара Садыйкова белән "Җидегән чишмә" җырын язу тарихын бәян иткән. "Чишмә моңы ничек җыр булды?" дип аталган текстны укытучылар, укучылар, мәктәп хезмәткәрләре язды. Киләсе елларда әти-әниләрне, авылдашларны да катнашырга чакырабыз.

***Рузилә Мөхәммәтова, XI сыйныф укучысы***

## *Мәктәп формасы ни өчен кирәк?*

**"Кешенең бөтен нәрсәсе матур булырга тиеш: киеме дә, йөзе дә, күңеле дә, фикере дә"**. А.П.Чехов әйтеп калдырган бу сүзләр бүген дә бик актуаль. Мәктәп формасы кигән укучы затлы да, җитди дә, эшлекле дә күренә. Бу кием укучыга үз-үзен тотышына да йогынты ясамый калмый, әлбәттә. Татарда киеменә карап каршы алалар, дигән әйтем дә бар бит әле. Бу таләпкә инде иялəшергә вакыт та кебек. Укучыларыбыз бу күрсәтмәләргә авыр буйсына, модада булган тар киемнәр киеп, әйтелгән тәртипләрне үтәмәскә тырышалар. Укучы формасы – мәктәптә генә киелергә тиешле кием. Ул – мәктәпнең визит карточкасы диярgә була. Шуңа күрә, укучылар да, әти-әниләр дә бу мәсьәләгә игътибарлырак булсагыз иде. Форма киеп алар билгеле бер тәртипкә, җаваплылыкка өйрәнәләр. Аның кечкенәдән урынына һәм вакытына карап кием кия белү гадәте формалашачак. Балада үз-үзен үстерү турында уйларга булышa диләр психологлар. Укучылар арасында социаль тигезлек тә урнаштыра. Шуңа күрә, мәктәпнең форма буенча куелган таләбенә буйсыну – кимсенү түгел. Киресенчә, ул шәхес формалашуга бер адым булып тора.



Мәктәбебездә бердәм форма 2014 нче елда яңа бина ачылган вакытта кертелгән иде. Безнең форма соры төстәге натураль материалдан тегелгән жакет-юбкадан һәм костюм-чалбардан гыйбарәт. Хәзерге вакытта мәктәптә форманы үзгәртү буенча мәсьәлә күтәрелде. Моңа тормыш тәҗрибәсеннән килеп туган берничә сәбәп этәрде. Беренчедән, киемне гадәттә кызлар гына тектерде. Малайларга төсе туры килгән костюм алырга кушылса да, кайберәүләр бу таләпне үтәмәде. Шуның өстенә, төсе туры килгән киемне табу да кыенлашты. Икенчедән, авыл шартларында катлаулы киемне оста итеп тегүчене табу авыр. Өченчедән, безнең форма өчен кулланылган материянең сыйфаты начарайды. Шуларны күздә тотып, быел укучыларга яңа формалар тектерү таләбен куймадык. Алдагы уку елын иске формалар белән тәгәлләячәкбез. Киләсе уку елына исә яңа төрдәге форма кертергә җыенабыз. Аның ниндирәк булачагы ата-аналар коллективы белән бергәләп киңәшеп хәл ителәчәк.

***Рузилә Хәйруллина, тәрбия эшләре буенча директор урынбасары***